Совет Старокакерлинского сельского поселения Дрожжановского муниципального района Республики Татарстан

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Какерле авыл җирлеге Советы

РЕШЕНИЕ

КАРАР

Иске Какерле авылы

2023 нче елның 1 нче августы №30/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле Муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге Уставының 32 статьясы белән Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге Советының 30.05.2022 № 20/2 карары белән расланган Нигезләмәгә (16.12.2022 № 24/3, 20.02.2023 № 26/1 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

26 нчы маддәнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

»- бюджет һәм акча йөкләмәләрен кабул итү һәм исәпкә алу;";

21 нче маддәнең 24 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бюджет проектын төзү: Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәте таләпләрен) билгеләүче Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Җыенына юлламасы нигезләмәләре;

Россия Федерациясенең милли үсеш максатларын һәм аларга ирешү буенча иҗтимагый хакимият органнары эшчәнлегенең юнәлешләрен билгеләүче документлар;

Россия Федерациясенең Бюджет, салым һәм таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләре (Россия Федерациясе субъектларының бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре, муниципаль берәмлекләрнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре);

социаль-икътисади үсеш фаразлары; бюджет прогнозы (бюджет прогнозы проекты, бюджет прогнозы үзгәрешләре проекты) озак вакытлы чорга;

дәүләт (муниципаль) программаларында (дәүләт (муниципаль) программалары проектларында, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектларында).».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге уставында билгеләнгән тәртип нигезендә Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Иске Кәкерле авыл җирлеге башлыгы,: Р.Ф.Фаткуллин